# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Хуҗәмәт авыл җирлегенең Усай торак пунктында
халык җыены нәтиҗәләре турында

**19.11.2020ел.** **№1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 10 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе түбәндәге мәсьәлә буенча төзелде: "2020 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Усай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1. Усай торак пунктында рус зираты коймасын ремонтлау (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

2. Усай торак пунктында татр зираты коймасын тоту (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган катнашучылар исемлегенә 122 халык җыенында катнашучы кертелгән, халык җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны - 63 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 63 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Усай торак пунктында халык җыены узуын таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. “2020 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Хуҗәмәт авыл җирлегенең Усай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә Сез ризамы?":

1. Усай торак пунктында рус зираты коймасын ремонтлау (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);

2. Усай торак пунктында татр зираты коймасын тоту (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

2. Хуҗәмәт авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Минзәлә муниципаль районының рәсми

сайтында (https://menzelinsk.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

**Халык җыенында рәислек итүче,**
**Минзәлә муниципаль районы**
**Хуҗәмәт авыл җирлеге башлыгы** ______________________ **Вилданова Г.Г.**
(имза) (тулысынча имза)